


# Габделҗәббар Кандалый

(1797— 1860)

# Тормыш юлы

* Габделҗаббар Габделмәҗит улы Кандалый 1797 елда Самара губернасы Ставрополь өязе (хәзерге Ульяновск өлкәсе Иске Майна районы) Иртуган (Иске Кандал) авылында мулла гаиләсендә туа.
* Башлангыч белемне Габделҗаббар үз атасыннан алган. Соңында Чистай якларындагы Мораса, аннары бер-бер артлы Кизләү, Күркәле, Кышкар, Шонталы мәдрәсәләрендә укыган.
* Г. Кандалый гарәп, фарсы телләрен өйрәнә. Рус, чуваш, мари авылларында еш булу, алар белән аралашу аңа бу телләрне дә үзләштерергә мөмкинлек бирә.

# Иҗатка килү юлы

* Шагыйрьнең әтисе Габделмәҗид ибн Ибнейәмин хәзрәт гади генә авыл мулласы булмыйча, заманына күрә зур укымышлы, китап-әсәр язу белән шөгыльләнүче кеше булган.
* Г. Кандалый кечкенәдән үк көчле рухлы, тынгысыз характерлы, уй-тойгыларын шигъри сөйләмгә салып бирергә оста булуы белән аерылып торган.
* Яшьтән үк ул шигырьләр яза башлый. Ул төрле гади эпиграммалардан һәм кечкенә сатирик шигырьләрдән башлап җибәрә. Мәсәлән, аны мәдрәсәдән куалагач, ул түбәндәге юллар белән җавап кайтара:

***Кусагыз да һич уфтанмам,***
***Язуымнан да тукталмам,***
***Котылмассыз барыбер сез,***
***Әле болай гына калмам.***

# Иҗаты үзенчәлекләре

* Г. Кандалый – лирик шагыйрь. Ул байтак шигырьләрен автобиографик материалга таянып яза. Беренче карашка бер-берсенә охшаш тоелсалар да. Аларның рухы, пафосы төрлечә. Шагыйрьнең башлангыч чор әсәрләренә яктылык, җиңеллек, юмор хас, аларда авторның яшь, дәртле, уен-көлке сөючән, мавыгучан кеше булуы сизелеп тора:

***Ки шау-шу: мәдрәсә гөрли..***

***Минем кальбем сәне уйлый,-***

Г. Кандалый заманының киң карашлы, тирән белемле кешесе булып формалаша. 30 нчы еллар азагында ул әтисе мәхәлләсенә кайта. Шагыйрьнең күпчелек әсәрләре шул чорда реаль шәхесләргә атап иҗат ителә.

* Г. Кандалый тормыштагы ямьсезлеккә каршы матурлык эталонын куйды: табигать кочагында үскән зирәк, эшчән, сәламәт җир кызын һәм лирик геройның аңа булган саф сөю хисен ачты. шунда ук хезмәт иясе авыл кызларының ул заманда кичергән авыр язмышларын да реалистик планда күрсәтә алды. Аның лирик герое еш кына мулла Габделҗаббар карашлары белән бәхәскә керә һәм җиңә. Бу яңа геройга нинди сыйфатлар хас соң? Иң элек, ул оптимист, ториыш матурлыгын, дөнья ләззәтен эзләүче.

* Г. Кандалының беренче шигырьләрендә үк реалистик предметлылык көчле. Әгәр шагыйрь искергән традицияләрне җимерергә үзен хаклы санаса, тормыш күренешләрен дини канунннардан аермалы аңлатырг омтылса, ахирәттән дә бигрәк җир тормышы белән кызыксынса- болар барысы реалистик иҗат тибының алшарты була ала. Г. Кандалый да образларны тормышның үзеннән табып тасвирлый.
* Г. Кандалый шигърияткә халыкчан таби-гыйлек, матурлык та алып килә. Бай поэтик традициягә һәм халык авыз иҗатына таянып, шагыйрь татар поэзиясен яңа баскычка күтәрә.

* Г. Кандалый иҗатының төп өлеше - мәхәббәт поэмалары һәм шигырьләре. Мәхәббәт темасы алгы планга куелу, беренче карашка, иҗтимагый активлыктан читләшү кебек тоелса да, реаль тормышны сүрәтләү, җир кешесен һәм аның табигый хисләрен олылау үзе үк, объектив рәвештә. шәригать кануннарына, иҗтимагый торгынлыкка каршы юнәлдерелгән куәтле протест авазы булып яңгырый.
* Г. Кандалый иҗатының нигезендә мәгъри-фәтчеләр күтәреп алган проблемалар ята. Җир кешесен күрсәтү, аның матурлыгын җырлау, кешен аң-белемгә өндәү - Г. Кандалый иҗатының көчле яклары. “Мәгърифәтчеләр, гомумән, кеше табигатен. аның бу дөньядагы урынын, чынбарлыкка мөнәсәбәтен ачыкларга тиешләр иде”.

# Әдәби мирасы

* Шагыйрь 1860 елда вафат була, үз авылында җирләнә. Тик хәзерге вакытта аның җәсәде кайда урнашканлыгын белүче кеше юк — Г. Кандалыйга кабер ташы да чама белән генә куела. Шулай ук шагыйрьдән калган әдәби мирасның төгәл күләме турында әйтеп булмый — аның кулъязмалары халыкка таралган, һәм илнең бөтен төбәкләреннән диярлек табыла торды.